ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**29.11.2022**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 3280**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Элек хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 20 гыйнварындагы 84 номерлы карары белән расланган, элек хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Административ регламентларны актуальләштерү максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Элек хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 20 гыйнварындагы 84 номерлы карары белән расланган элек хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертергә.

1.1.3.3.2.1 пунктының унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «3.3.2.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасында һәр юлын тутыру процессында формалаштырылган рәсми мөрәҗәгатьне формаль-логик тикшерү, орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, Бердәм порталда автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасында дөрес тутырылмаган юллары ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасында мәгълүмати хәбәр аша җиткерелә.».

2. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин